**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Нижнекамский городской**
**С О В Е Т**

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) 42-51-76, тел.42-42-66

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Түбән Кама шәһәр**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр12
факс (8555) 42-51-76, тел.42-42-66

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 21** **2 сентябрь 2010 ел**

**«Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турында»гы Түбән Кама шәһәр Советының 2009 елның 28 нче гыйнваренда кабул ителгән 6 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының (алга таба — муниципаль вазыйфаны биләүче затларның) хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 елдагы 2 нче 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 6 статьялары нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2009 елның 28 нче гыйнвары 26 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 абзацка өстәргә:

- кушымта нигезендә Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе һәм шартлары.

- 2 пунктны түбәндәге тәкъдим белән тулыландырырга: Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлекнең муниципаль вазыйфасын биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе һәм шартлары Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затларга кагыла.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре мэры урынбасары Р. И. Миңнуллинга йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2010 елның 21 сентябре
21 номерлы карарына
**кушымта**

Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе һәм шартлары

1. Муниципаль хезмәттән эштән киткәндә муниципаль вазифа биләүче затларга, тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда һәм муниципаль хезмәтнең һәр тулы елы өчен өстәмә 0,5әр күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләнә, ләкин муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның акчалата кеременнән уннан тапкырдан артмаска тиеш. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәттән азат ителгән көнгә билгеләнә.

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затлар бер тапкыр бирелә торган бүләк алу хокукына ия:

1) муниципаль вазыйфаны кимендә бер ел эшләү һәм муниципаль яки дәүләт вазыйфаларын эшләү буенча гомуми срок (стаж), дәүләт граждан хезмәте яки муниципаль хезмәт стажы кимендә 15 ел булу;

2) вәкаләтләр туктатылуга бәйле рәвештә (шул исәптән вакытыннан алда) вазыйфадан азат итү, гаепле гамәлләргә бәйле вәкаләтләр туктатылу очракларыннан тыш;

3) «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында»17.12.2001 ел, № 2 173-ФЗ Федераль закон нигезендә картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясен билгеләү.

2. Әлеге статьяда каралган бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү турындагы карар, тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыгу сәбәпле, эштән китү турында карар белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

3. Муниципаль пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләк муниципаль вазыйфаны биләүче затлар үз вәкаләтләрен башкара торган орган тарафыннан түләнә.

4. Тиешле елларны эшләгән өчен муниципаль пенсиягә чыканда, акчалата бүләк бер тапкыр түләнә. Граждан муниципаль хезмәткә кергәндә, тиешле еллар эшләгән һәм аннан соңгы еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәт туктатылганнан соң, әлеге статьяда каралган бер тапкыр бирелә торган бүләк кабат түләнми.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү җирле бюджет акчаларыннан гамәлгә ашырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Р. Миңнуллин